Минһаҗева, З. Бар дә әйбәт булачак / З. Минһаҗева // Көмеш кыңгырау. – 2025. – №20 (24 май). – Б. 3.



**Зөләйха МИНҺАҖЕВА,**
шагыйрь Татарстанның
атказанган
мәдәният хезмәткәре

# Бар да әйбәт булачак

Мин, Идиятуллина Зөләйха Мохиулла кызы, 1971 елда Татарстанның Баулы районы Яңа Шалты урта мәктәбен тәмамладым. Ул ел, ул көн сәгате-минуты белән хәтердә саклана. Чыгарылыш сыйныфлары өчәү иде. Шаулап торган ярты мәктәп укучысы. Укытучылар безнең белән шактый интеккән булсалар да, без киткәч, бик ямансулап калганнардыр, мөгаен.

Бәйрәмгә ярты ел алдан әзерләнә башладык. Программа төзеп авылларда концертлар куеп, чыгарылыш кичәсенә акча җыйдык. Шакмаклы дәфтәрдән билеттар ясадык. (Тиз һәм тигез яртылсын өчен, тегү машинасы белән йөртеп чыктык). “Ялкын” концерт төркеме дигән штапм ясатып алдык. 20 тиен дип билет бәясе яздык та һәр билетка мәктәп печате суктырып алдык. Чыгарылыш кичәсенә, яраткан укытучыларыбызга бүләккә – барына да җитте.

Чыгарылыш кичәсенең үзәгендә да без – инде концертлар куеп, шомарып беткән «Ялкын» концерт төркене булды бугай. Яңгырлы көн иде. Таң беленә башлагачөйләребезгә таралыштык. Мин түфлиләрекне салып, яланаяк кайттым. Бер урамчан 8 укучы. Бик арылган булса да, өйгә керәсе килми.Күңел кызык бер халәттә. Узганы -ябылган, киләчәге - билгесез. Ә шулай да, бар да әйбәт булачагына, киләчәкнең искиткеч матур буласына күңелдә ышаныч бар иде. Әнә бит, ничек матур булып, дөньяны яктыртып яңа таң атып килә...




Сәхифәне Гөлинә ГУСАМОВА әзерләде.